ГЛАВА ЯМБУЛАТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Центральная, д.5, с.
Ямбулатово,
422587

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯМБУЛАТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Узәк ур., 5 нче йорт, Ямбулат авылы,
422587

Тел.: (84379) 36-5-18 факс: (84379) 36-5-18

07 декабря 2021г. № 1

КАРАР
Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге Казыльяр авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге Казыльяр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2022 елда 6800 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә риза буласызмы? " мәсьәләсе буенча 2021 елның 7 декабрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

- Кызыльяр авылындагы Урман урамы буенча юлга вак таш салу.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашкан 5 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 5кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен тавыш бирде 5 халык җыенында катнашучы; «Юк» позициясе өчен тавыш бирде 0 җыенда катнашучы.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге Казыльяр авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре дөрес дип танылды.

2. 2. «Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге Кызыльяр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, авыл җирлеге Башкарма комитеты карары белән билгеләнгән ташламалы категориядән тыш, балигъ булган һәр кешедән 2022 елда 6800 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә риза буласызмы? " дигән сорау буенча карарны таныргa:

- Кызыльяр авылындагы Урман урамы буенча юлга вак таш салу.

3. Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге Кызыльяр авылында халык җыенының нәтиҗәләрен Ямбулат авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче А.Н.Макаров